КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь г.Казань № 1200

Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов
истәлеген мәңгеләштерү турында

Советлар Союзы Герое Кузнецов Борис Кириллович истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Советлар Союзы Геройларының, Социалистик Хезмәт Геройларының, Россия Геройларының һәм Татарстан Республикасы Сугыш һәм Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалерларының иҗтимагый хәйрия оешмасы тәкъдимнәрен кабул итәргә:

Казан шәһәре, Достоевский урамы, 53 нче йорт адресы буенча йорт фасадына Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецовка татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турында, ул анда 1979 елның 3 апреленнән 2008 елның 24 ноябренә кадәр яшәгән:

"Бу йортта 1979 - 2008 елларда Советлар Союзы Герое Борис Кириллович Кузнецов яшәде

---

В этом доме в 1979 – 2008 гг. жил Герой Советского Союза Борис Кириллович Кузнецов»;

"Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат-мәктәбе" дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе территориясендә Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецовның бюстын урнаштыру турында.

2. Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының тәкъдимен кабул итәргә:

урамга Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемен бирү яки урамны аның хөрмәтенә үзгәртү турында;

2021 елның 9 маена Лаеш муниципаль районындагы Җиңү аллеясында Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецовның бюстын ачу турында.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) һәм Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) белән берлектә әлеге карарны гамәлгә ашыру, шул исәптән Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов бюстларын проектлау буенча эш оештырырга.

4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына һәм Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

югарыда күрсәтелгән бюстларны әзерләү һәм урнаштыру, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү буенча заказчы функцияләрен үз өстенә алырга;

югарыда күрсәтелгән бюстларның баланс тотучыларын билгеләргә.

5. 5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин